**Татарстан Республикасы буенча Россия гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре идарәсе**

**420066, Казан ш., Ф.Яруллин ур., 1 й.**

# Янгын куркынычсызлыгы: дөрес ял итегез

**! 2022 елның 25 апреленнән 15 маена кадәр Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертелә, аның нигезендә түбәндәге кагыйдәләр :**

- учаклар төртү, каты калдыкларны, коры үләнне һәм чүп-чарны яндыру тыела;
- ачык утта ризык әзерләү һәм җылылык белән эшкәртү өчен махсус янмый торган савытлар (мангал һ.б.) кулланыгыз. җәмәгать туклануы объектлары (ресторан, кафе һәм башка) территорияләрендә урнашкан һәм эксплуатацияләнә торган мангаллар һәм башка җайланмалар санауга керми. Лэкин  урман һәм башка ландшафт (табигый) җирлэргэ янгын куркынычы булган торак пунктларда, гражданнар тарафыннан бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территорияләрендә (алга таба бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәте), балалар ялы һәм аларны савыктыру оешмалары территорияләрендә, шулай ук урман янгыннары белән чиктәш булган объектларында һәм урман массивлары белән чиктәш булган территорияләрдә урман янгыннары чыгу куркынычы янаган җирлэргэ торак пунктларда ачык ут белэн куллану һәм ачык утта ризык әзерләү кисэтелэ;
- торак пунктлар территорияләрендә, урман янгыннарына һәм башка ландшафт (табигый) янгыннарына, балаларның ялына һәм аларны савыктыру оешмаларына, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләренә, урман янгыннарына, савыктыру оешмаларына, шулай ук икътисад объектларында, урман-парк зоналарында, торф участокларында һәм урман массивлары белән чиктәш ачык территорияләрдә куркыныч янаган 1-3 классы пиротехника эшләнмәләре куллану кисэтелэ;
- югары күтәрелү принцибы конструкцияләр эчендә һаваны җылытуга нигезләнгән янучан материаллардан идарәче булмаган эшләнмәләр җибәрү кисэтелэ.

***Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу административ штраф салуга китерә:***

*гражданнарга - 2000-4000 сум;*
*вазыйфаи затларга - 15000-30000 сумнан;*
*эшкуарлык эшчәнлеген юридик зат төземичә гамәлгә ашыручы затларга - 30000-40000 сумнан;*
*юридик затларга - 200000-400000 сумнан.*

## Табигатьтә янгын куркынычсызлыгы

- җиһазландырылмаган урыннарда ачык ут белән файдалану тыела;
- шырпыны, тәмәке төпчекләрен һәм тәмәке көпшәләреннән янган көлне ташлау тыела. Ташлап китәр алдыннан аларны яхшылап томаларга кирәк;
- шешәләрне яки пыяла кисәкләрен (кояшта алар зурайткыч пыялалар кебек эшлиләр, кояш яктысын фокуслыйлар һәм үлән, мүк һ. б.яндыралар) яндыру тыела, шулай ук янгын матдәләр белән майланган яисә сеңгән материаллар (кәгазь, тукыма һ. б.) белән куллану тоела;
- үлән, чүп-чар, тирәк мамыгы, камыл яндыру тыела;
- корыган үләнле урыннарда, агачларның ябалдашлары астында, шулай ук

**Татарстан Республикасы буенча Россия гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре идарәсе**

**420066, Казан ш., Ф.Яруллин ур., 1 й.**

# янгын куркынычсызлыгы: дөрес ял итегез

җимерелгән урман участокларында учак ягу тыела;

- яныып торган үлән яныннан узмагыз, янгынны үз көчегез белән сүндерә алмасагыз, “01”, “101”, “112” телефоннары буенча янгын сагына шалтыратыгыз.

Ачык утта ризык әзерләү янгын куркынычсызлыгының билгеле бер таләпләрен үтәгәндә һәм территориядә янгынга каршы махсус режим булмаса рөхсәт ителә.

## Янмый торган савытларда (мангал, барбекю, мичләр) ризык әзерләгәндә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре:

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә караган бакча участокларында якындагы корылмаларга кадәр кимендә 5 метр ара булырга тиеш;
- ачык ут чыганагыннан 2 метр радиуста территорияне янучан материаллардан чистартырга кирәк;
- агач ботаклары астында яисә урман утыртмалары янында азык әзерләү җайланмаларын урнаштыру тыела;
- очып китүче очкыннар янгынга сәбәп булырга мөмкин, шуңа күрә янәшәдә җиңел янып китүчән сыеклыклар һәм материалларны урнаштыру тыела;
- шәһәр читендәге йорт ишегалдында, яну продуктлары корылмаларга эләкмәсен өчен, мангал урнаштыру өчен махсус урын бирелергә тиеш;
- ачык ут чыганагын күзәтүсез калдыру, шул исәптән аның артыннан күзәтүне балаларга тапшыру тыела;
- ут чыганагы янында су яки янгын сүндерү җайланмасы урнаштырырга кирәк.

## Ризык әзерләгәннән соң кирәк:

- мангалны металл битлек, капкач белән капларга һәм күмер тулысынча янып чыгуын күзәтергә;
- файдаланылган суынган күмерне махсус кыскычлар ярдәмендә су салынган савытка салырга яки комга күмергә кирәк;
- ял итү урынын калдырып киткәндә, чүп-чарны махсус билгеләнгән урынга чыгарып, җыярга кирәк.

**Татарстан Республикасы буенча Россия гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре идарәсе түбәндәгеләрне искә төшерә: «Ут белән эш итүдә сак булыгыз, аннан файдаланганда уяулык күрсәтегез һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәгез»**